ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.10.2019 | Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48 | 02

с. Коргуза

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 5ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Егидерево авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 300 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Егидерево авылында суүткәргечне ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Егидерево ФАП бинасы янында: Егидерево ав., Центральная ур., 28 йорт адресы буенча 13.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Карагуҗа авыл җирлеге**
**Башлыгы** **С.А.Сакин**